# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘҖМӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

13.01.2020 г №94

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Әҗмәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлегендә муниципаль
хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның
6 декабрендәге 63-2 номерлы карары белән расланган Татарстан
Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлегендә муниципаль
хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү турында(2019 елның 16 июлендәге 77-1,24 июлендәге 78 номеры
үзгәрешләре белән)

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Әҗмәр авылҗирлеге советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авылҗирлеге Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 6 декабрендәге 63-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә(2019 елның 16 июлендәге 77-1, 24 июлендәге 78 номерлы үзгәрешләре белән)түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12.1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәянитәргә:

«2)түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәриберлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак төзелеше, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж

кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;

в) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулайук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешма идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибенә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;";

12.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча белән өстәргә:

«2.1) эш куарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;».

2.Әлеге карарны Әҗмәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru), һәм хокукый мәгълүмат сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль

районы Әҗмәр авыл җирле башлыгы Р.М.Вәлитов.

